КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 октябрь г.Казань № 928

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2011 ел, 21 сентябрь, 784 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2011 ел, 21 сентябрь, 784 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 18 декабрь, 1101 нче; 2013 ел, 24 май, 349 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2015 ел, 19 март, 167 нче; 2015 ел, 22 июль, 539 нчы; 2017 ел, 22 сентябрь, 710 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 949 нчы; 2019 ел, 8 июль, 558 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлегенә, «Экология күзәтчелеге дәүләт инспекциясенең әйдап баручы консультантлары, 1 разрядлы өлкән белгечләре; территориаль идарәләрнең 2, 3 разрядлы өлкән белгечләре, 1 разрядлы белгечләре; территориаль идарәләрнең махсуслаштырылган инспекцияләре башлыклары, башлык урынбасарлары, баш белгечләре, әйдап баручы белгечләре» юлында «2, 3 разрядлы өлкән белгечләре» сүзләрен «консультантлары, 2, 3 разрядлы өлкән белгечләре» сүзләренә алыштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин